| | |
|---|---|
| **ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ НИЖНЕТИМЕРЛЕКСКОГО СЕЛЬСКОГО ПОСЕЛЕНИЯ РЫБНО-СЛОБОДСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН**<br>422670, с. Верхний Тимерлек,<br>ул.Советская 72А | **ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ БАЛЫК БИСТӘСЕ МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ ТҮБӘН ТЕГЕРМӘНЛЕК АВЫЛ ҖИРЛЕГЕ БАШКАРМА КОМИТЕТЫ**<br>422670, Югары Тегермәнлек авылы,<br>Совет урамы,72А йорт |

Тел.: (884361) 28001, факс: (884361) 28001, e-mail:Ntim.RS@tatar.ru сайт: ribnaya-sloboda.tatarstan.ru

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

28.11.2022 ел Югары Тегермәнлек ав. № 11

Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районының Түбән Тегермәнлек авыл җирлеге Башкарма комитетының 2022 елның 10 мартындагы 3 нче номерлы карары белән расланган белешмә (өземтә) бирү буенча муниципаль хезмәт күрсәтүнең административ регламентына үзгәрешләр кертү турында

Россия Федерациясе Хөкүмәтенең 2022 елның 15 августындагы «Россия Федерациясе Хөкүмәтенең кайбер актларына үзгәрешләр кертү турында» 1415 номерлы карары, «Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районы җирле үзидарә органнары тарафыннан муниципаль хезмәтләр күрсәтүнең административ регламентларын эшләү һәм раслау тәртибен раслау турында»Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районы Башкарма комитетының 11.02.2022 №28пи карары нигезендә КАРАР БИРӘМ:

1. Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районының Түбән Тегермәнлек авыл җирлеге Башкарма комитетының 2022 елның 10 мартындагы 3 нче номерлы карары белән расланган белешмә (өземтә) бирү буенча муниципаль хезмәт күрсәтүнең административ регламентына (алга таба – Регламент) түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

3.3.2.1 пунктының 11 абзацын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«Тәгъбирләнгән гарызнамәне формат-логик тикшерү Бердәм портал тарафыннан орган (оешма) билгеләгән таләпләр нигезендә мөрәҗәгать итүченең гарызнамәнең һәрбер электрон форма кырын тутыруы процессында автоматик рәвештә гамәлгә ашырыла. Бердәм портал тарафыннан гарызнамәнең дөрес тутырылмаган электрон формасындагы кырны ачыклаганда мөрәҗәгать итүчегә ачыкланган хатаның характеры һәм аны төзәтү тәртибе турында электрон формада хәбәр ителә.».

2. Әлеге карарны Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районы Түбән Тегермәнлек авыл җирлегенең Татарстан Республикасы, Балык Бистәсе муниципаль районы, Югары Тегермәнлек авылы, Совет урамы 72А адресы буенча урнашкан махсус мәгълүмат стендында һәм Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районының http://ribnaya-sloboda.tatarstan.ru. веб-адресы буенча Интернет мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендәге рәсми сайтында һәм http://pravo.tatarstan.ru. веб-адресы буенча Интернет мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендәге “Татарстан Республикасының хокукый мәгълүмат рәсми порталы”нда урнаштырырга.

3. Карарның үтәлешенә контрольлек итүне үземнең җаваплылыкта калдырам.

Татарстан Республикасы
Балык Бистәсе муниципаль
Районы Түбән Тегермәнлек авыл
җирлеге башлыгы А.Ш.Альмиев